ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.11.2022 Казан ш. №566-145/кс-2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 12 сентябрендәге 1188 номерлы карары белән Алабуга шәһәрен салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу схемасына үзгәрешләр кертелүгә, Алабуга шәһәрен, «Алабуга» махсус икътисадый зонасы, «Три Медведя» коттедж поселогы территориясен су белән тәэмин итү схемаларын берләштерүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 17 ноябрендәге 38-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте өчен 2021-2025 елларга эчәргә яраклы суга тарифлар билгеләү хакында» 30.11.2020 №325-136/кс-2020;

«Алабуга» сәнәгый-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.11.2020 №325-136/кс-2020 карарында билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 ел өчен төзәтмә кертү хакында» 10.12.2021 №493-151/кс-2021.

2. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев